# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 22 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6, (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 9 август, 18 октябрь, 4 ноябрь, 23 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"гражданнарга – бер меңнән алып ике мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.";
б) түбәндәге эчтәлекле өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:
"Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен –
гражданнарга – ике мең биш йөздән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз меңнән алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.";

2) 3.6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.6 статья. **Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу**

Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен –

гражданнарга – ике меңнән алып өч мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен –

гражданнарга – өч мең биш йөз сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз меңнән алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.";

3) 4.1 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"гражданнарга – бер меңнән алып ике мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.";

б) түбәндәге эчтәлекле өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:

"Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен –

гражданнарга – ике мең биш йөздән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз меңнән алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.";

4) 4.2 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"гражданнарга – биш йөздән алып ике мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.";

б) түбәндәге эчтәлекле өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:

"Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен –

гражданнарга ике мең биш йөздән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз меңнән алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 1-ТРЗ